КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 2 март г.Казань № б-332

1. Мәгариф өлкәсендә бюрократик йөкләнешне киметү барышларын оптимальләштерү буенча ведомствоара эшче төркем төзергә.

2. Бу карарга теркәлгән Мәгариф өлкәсендә бюрократик йөкләнешне киметү барышларын оптимальләштерү буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 2 март, б-332 нче
боерыгы белән расланды

# Мәгариф өлкәсендә бюрократик йөкләнешне киметү барышларын оптимальләштерү буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә бюрократик йөкләнешне киметү барышларын оптимальләштерү буенча ведомствоара эшче төркем турында әлеге нигезләмә Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә бюрократик йөкләнеш барышларын оптимальләштерү һәм аны киметү буенча ведомствоара эшче төркемнең хокукый статусын, максатларын, бурычларын, функцияләрен, составын, аны формалаштыру тәртибен, аның компетенциясен, эшчәнлеген оештыруны һәм документация белән тәэмин итүне билгели.

2. Ведомствоара эшче төркем Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә бюрократик йөкләнешне киметү барышларын оптимальләштерү максатларында төзелгән координация органы булып тора.

## II. Ведомствоара эшче төркемнең бурычы һәм функцияләре

1. Ведомствоара эшче төркем бурычы – Татарстан Республикасы мәгариф өлкәсендә бюрократик йөкләнеш барышларын оптимальләштерү һәм аны киметүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырганда республика башкарма хакимият органнарының нәтиҗәле үзара эшләвен тәэмин итү.

2. Эшче төркем функцияләре:

планнарны, ведомствоара рәсми сорауларны, педагогик хезмәткәрләргә йөкләнгән эшләрне, шул исәптән аларның «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ Федераль законның 47 статьясындагы $6^1$, $6^2$ өлешләренә, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программаларын, урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашырганда педагогик хезмәткәрләр тарафыннан әзерләнә торган документлар исемлеген раслау турында» 2024 елның 6 ноябрендәге 779 номерлы боерыгына туры килү-килмәвенә анализ ясау;

документация йөкләнешен киметү өлешендә мәгариф өлкәсендәге законнар таләпләрен нәтиҗәле үтәү максаты белән мәгариф оешмалары катнашында ведомствоара чараларны оптимальләштерү һәм актуальләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

бюрократик йөкләнешне киметүгә комачаулый торган яшерен механизмнарны ачыклау;

ведомствоара эшче төркемнең карар проектына кертү өчен карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү.

## III. Ведомствоара эшче төркем составы

1. Ведомствоара эшче төркем түбәндәге составта төзелә: ведомствоара эшче төркем рәисе, ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасарлары, ведомствоара эшче төркемнең җаваплы сәркатибе һәм ведомствоара эшче төркем әгъзалары.

2. Ведомствоара эшче төркем составына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, мәгариф оешмалары, шулай ук башка оешмалар вәкилләре кертелә.

3. Ведомствоара эшче төркем эшендә катнашу өчен, кирәк булганда, ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге мәсьәләләре буенча аның әгъзалары булып тормаган экспертлар һәм белгечләр җәлеп ителергә мөмкин.

4. Ведомствоара эшче төркемнең персональ составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

## IV. Ведомствоара эшче төркем эшчәнлеген оештыру

1. Ведомствоара эшче төркемнең төп эшчәнлек формасы – турыдан-туры яки читтән торып үткәрелә торган утырыш.

2. Ведомствоара эшче төркем рәисе:

ведомствоара эшче төркем эшчәнлеген оештыра;

ведомствоара эшче төркем әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, вазыйфаларның үтәлешен координацияли һәм контрольдә тота;

ведомствоара эшче төркем утырышларын уздыру датасын, урынын, вакытын һәм тәртибен билгели;

ведомствоара эшче төркем утырышларын алып бара;

ведомствоара эшче төркем утырышы беркетмәсенә имза куя.

3. Ведомствоара эшче төркем рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын аның кушуы буенча ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасарларының берсе башкара.

4. Ведомствоара эшче төркемнең җаваплы сәркатибе ведомствоара эшче төркем утырышларына материаллар әзерләүне, ведомствоара эшче төркем әгъзаларына утырыш үткәрү көне, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат җиткерә, ведомствоара эшче төркем утырышы беркетмәсен алып бара.

5. Ведомствоара эшче төркем әгъзалары:

ведомствоара эшче төркем утырышларында катнаша;

утырышта карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча материаллар әзерләүдә һәм шундый мәсьәләләр буенча материаллар проектларын тикшерүдә катнаша;

ведомствоара эшче төркем рәисе йөкләмәләрен башкара.

6. Ведомствоара эшче төркем составының яртысыннан күбрәге катнашканда, утырыш тулы хокуклы булып санала.

Эшче төркем утырышларында карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча карарлар ведомствоара эшче төркем әгъзалары утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышлары белән ачык тавыш биреп кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

7. Ведомствоара эшче төркем утырышында кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, ведомствоара эшче төркем әгъзалары үзләренең махсус фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы, ул ведомствоара эшче төркем утырышы беркетмәсенә теркәлергә тиеш.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 2 март, б-332 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә бюрократик йөкләнешне киметү барышларын оптимальләштерү буенча ведомствоара эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, ведомствоара эшче төркем рәисе |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасары |
| Захарова Светлана Николаевна | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе, ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасары |
| Мөхәррәмова Гүзәл Шамил кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаментына караган контроль-күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы, ведомствоара эшче төркем рәисенең җаваплы сәркатибе |

Ведомствоара эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Амрахова Флера Әдһәм кызы | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә караган эпидемиология күзәтчелеге бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе рәисе урынбасары |

| | |
|---|---|
| Галиева-Мостафина Софья Альфред кызы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрның беренче урынбасары |
| Җәләлева Анфиса Григорьевна | «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры |
| Карпова Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә караган балалар һәм яшүсмерләр гигиенасына күзәтчелек бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Козырева Фәния Фәис кызы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының фәнни тикшеренүләр, инновацияләр һәм һөнәри компетенцияләрне үстерү бүлеге башлыгы |
| Наумова Эльвира Викторовна | Казан шәһәре Яңа Савин районының «179 нчы гимназия – мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Петручик Татьяна Борисовна | «Казан шәһәре Яңа Савин районының «Катнаш төрдәге 151 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире (килешү буенча) |
| Проценко Ирина Николаевна | Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәри берлегенең Татарстан Республикасындагы төбәк оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Прытков Евгений Александрович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Сибгатов Илнур Заһит улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Трущин Максим Владимирович | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы урынбасары – күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсе башлыгы (килешү буенча). |